**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлегенең Түбән Кенә авылында**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2024 ел 12 ноябрь № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Карадуган авыл җирлегенең Түбән Кенә авылыда халык җыены турында карар бирә:

1. 2025 елда Балтач районы Карадуган авыл җирлеге Түбән Кенә авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзсалым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

-җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Кәлимулла чишмәсен төзекләндерү);

-урамнарны яктырту җайланмасы кую (Школьная урамына урам уты урнаштыру);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Новая, Бакый Рәхимов, Подгорная урамнары буенча юлларны ремонтлау.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында ( pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе: Ш. В. Низамиев